**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ X УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 17**

Шуган ав. 15 апрель 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» Шуган авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү турында**

Мөслим муниципаль районының Шуган авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 27 декабрендә 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 2 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

2. ««Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Шуган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советының 2021 елның 07 апрелендәге 16 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Шуган авыл җирлеге башлыгы Басорина А.Ю.**